**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **16 май, 2022 ел** | **№ 169** |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның14 статьясының 1 өлешендәге 20 пункты нигезендә, 2022 елның 17-19 февралендәге ачык тыңлаулар беркетмәләрен, 2022 елның 19 февралендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2020 елның 22 июнендәге 677 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров

Биектау авыл җирлегенең Генераль планы материаллары белән ФГИС ТП сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) танышырга мөмкин.